СОВЕТ КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

24 сентябрь 2018 ел № 2-33

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көмеш-Күл авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көмеш-Күл авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 20 сентябрендәге «Референдум үткәрү инициативасы турында» 10 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 2014 елның 2 апрелендәге №2-30карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көмеш-Күл авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турында Нигезләмә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 2014 елның 2 апрелендәге 2-30 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турындагы Нигезләмә (17.09.2018 № 5-32 карар редакциясендә) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көмеш-Күл авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: «"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү .

-Көмеш-Күл, Алгай һәм Зур Өске торак пунктларындагы артезиан скважиналарын алырга;

2.Зур Өске торак пунктында су башнясын әйләндереп алырга;

3.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру:

- авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.
- Көмеш-Күл торак пункты Үзәк урам һәм Алгай торак пунктында Зур урам ягына баручы юлны вакташ җәеп ремонтлау;

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сәләхетдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Н.Сәләхетдинов